# КАРАР

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Иске Теләкәй авылында гражданнарның үзарасалым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

26 ноябрь 2025 ел № 2

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Теләкәй авыл җирлеге Иске Теләкәй авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Теләкәй авыл җирлеге Иске Теләкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар, көндезге формада укучылар, 90 яше тулган хэм анан олкэн яшьтэгеләрдән тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000 сум үзарасалым кертү белән килешәсезме?:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:
   – (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
   - ( урам юлларын карап тоту хэм ремонтлау)

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү, ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:
   – (хуҗасыз ихаталарга койма кору)

4. Һәйкәлләрне Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
   – ( Һәйкәлләр территориясен төзекләндерү)

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 238 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 81 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 81 граждан тавыш бирде;<br>
"каршы" позициясе өчен _0_ граждан тавыш бирде.<br>
"тоткарланучылар" позициясе өчен _0_ граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Teләкәй авыл җирлеге Иске Teләкәй авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Teләкәй авыл җирлеге Иске Teләкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар , көндезге формада укучылар, 90 яше тулган хэм анан олкэн яшьтэгеләрдән тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 1000 сум үзарасалым кертү белән килешәсезме?:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

– (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- ( урам юлларын карап тоту хэм ремонтлау)

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү, ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:

– (хуҗасыз ихаталарга койма кору)

4. Һәйкәлләрне Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

– (Һәйкәлләр территориясен төзекләндерү)

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Teләкәй авыл җирлеге гражданнар Җыенының «Актаныш муниципаль районы Teләкәй авыл җирлегенең Иске Teләкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»15.11.2024 ел, № 2 карары 6 нчы пункты «Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, калдыкларны чыгару» үз көчен югалткан дип танырга.

4. Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта, Teләкәй авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенында билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

5. Teләкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Teләкәй авыл җирлеге Башлыгы И.Т.Гайнетдинов